Республика Татарстан
**ГЛАВА**
Пестречинского
муниципального района –
председатель Совета
Пестречинского
муниципального района
422770, с.Пестрецы, ул. Советская, 18

Татарстан Республикасы
Питрәч муниципаль районы

**БАШЛЫГЫ –**

Питрәч муниципаль район
Советы рәисе
422770, Питрәч авылы, Совет урамы, 18

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«25» август, 2021 ел № 123-п

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының Яңа Шигали авылында кадастр номерлары 16:33:181614:681, 16:33:181614:685 булган җир кишәрлекләрендә «Усадьба Царево-2» торак комплексы территориясен планлаштыру проектын карау буенча гавами тыңлаулар билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы уставы, Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Советының 2015 елның 30 гыйнварындагы 3/224 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы территориясендә гавами тыңлауларны оештыру һәм уздыру тәртибе турында нигезләмә нигезендә, Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районында яшәүчеләрнең хокукларын һәм мәнфәгатьләрен үтәү максатларында **карар бирәм**:

1. Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының Яңа Шигали авылында кадастр номерлары 16:33:181614:681, 16:33:181614:685 булган җир кишәрлекләрендә «Усадьба Царево-2» торак комплексы территориясен планлаштыру проектын карау буенча гавами тыңлаулар билгеләргә.

2. Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Башкарма комитетына һәм Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Шигали авыл җирлеге башкарма комитетына территорияне планлаштыру проектын карау буенча гавами тыңлаулар оештырырга һәм үткәрергә.

3.Билгеләргә:

3.1. гавами тыңлаулар үткәрү датасы һәм вакыты - 27.09.2021 елда 10.00 сәгатьтә;

3.2. үткәрү срогы - 1 көн;

3.3. Үткәрү урыны - Шигали авыл мәдәният йортының тамаша залы, адресы: Татарстан Республикасы, Питрәч районы, Шигали авыл җирлеге, Иске

Шигали ав., Үзәк ур., 45 й.

3.4. гавами тыңлауларда катнашу өчен заявкалар бирү вакыты - 24.09.2021 елга кадәр;

- язма рәвештә, көн саен 08.00 сәгатьтән 12.00 сәгатькә кадәр, 13.00 сәгатьтән 17.00 сәгатькә кадәр Шигали авыл җирлеге башкарма комитетына түбәндәге адрес буенча: ТР, Питрәч районы, Шигали авыл җирлеге, Иске Шигали авыл җирлеге, Үзәк ур., 45 йорт, гражданнар өчен күрсәтелгәнчә: фамилия, исем, атасының исеме, яшәү урынын, эш урынын һәм билгән вазыйфаны теркәү адреслары, контакт телефоннары; гражданнар төркеме өчен - фамилияләре, исемнәре, аталарының исемнәре, кайсы да булса иҗтимагый оешмаларга яисә оешмаларга (әгәр булса) каравы, яшәү урыннары, юридик затлар өчен телефон, аларның бланк номерлары, оешма җитәкчесенең исеме, фамилиясе, һәм этисенең исеме күрсәтелә.

4. Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының Шигали авыл җирлеге башкарма комитетына:

4.1. «Вперед» («Алга») район газетасында гавами тыңлаулар үткәрү турында мәгълүмат бастырырга;

4.2. Территорияне планлаштыру проекты буенча билгеләнгән тәртип һәм әлеге карар белән билгеләнгән срокларда гавами тыңлаулар әзерләргә һәм уздырырга.

5. Территорияне планлаштыру проекты буенча гавами тыңлауларга чыгарылган тәкъдимнәр һәм искәрмәләр кызыксынган затлар тарафыннан Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Шигали авыл җирлеге башкарма комитетына, эш көннәре буенча мәгълүмат бастырылганнан (халыкка җиткерелгәннән), 24.09.2021 елга кадәр (шул көнне кертеп) 8.00 сәгатьтән 12.00 сәгатькә кадәр, 13.00 сәгатьтән 16.00 сәгатькә кадәр, ТР, Питрәч районы Шигали авыл җирлеге башкарма комитетына түбәндәге адрес буенча тапшырылырга мөмкин: ТР, Питрәч районы, Шигали ав., Үзәк ур., 45.

6. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) һәм Питрәч муниципаль районының рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

7. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

8. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Татарстан Республикасы
Питрәч муниципаль районы башлыгы И.М. Кашапов

СОВЕТ ПЕСТРЕЧИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА